# «Буыннан-буынга. Из поколения в поколение»

Сведения об авторе: Гилязова Розалия Гумаровна,
педагог дополнительного образования
муниципального бюджетного учреждения
дополнительного образования
«Центр внешкольной работы
Зеленодольского муниципального района
Республики Татарстан»

пгт Васильево 2021

*Бөек татар халкын, бай тархихын,*
*Гасырлардан килгән мирасын,*
*Калдырасы иде яшь буынга,*
*Һәрбер кеше барлап соклансын!*
*Гореф- гадәтләрне, җыр- биюне,*
*Сабан туен, Җыен, Нәүрүзен,*
*Белсен иде җирдә һәрбер бала*
*Әнисеннән алган үз телен*

Бүгенге көндә үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый. Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү.

Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә. Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләгәндә татар халкының электән килгән

гореф-гадәтләре , мәдәнияте белән кызыксынучы югары әхлаклы, һәряклап үсеш алган, иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудырыла.

Бүгенге көндә үз алдыма куйган бурычларның иң мөһиме – балаларга максатлы рәвештә - үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары , милли әдәбияты белән таныштыру.

Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф гадәтләренә таяну. Үз телен яратучы, милләтен хөрмәтләүче кешене тәрбияләүне халык педагогикасына таянып эш итү зарур. Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак.

Милли бәйрәмнәр, татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары онытыла бару сәбәпле, бер-беребез белән аралашу, очрашулар сирәгәя бара. Хәтта авыл җирендә дә бер-берсен белмәүче кешеләр бар. Бүгенге көндә күп кенә өлкәннәребез дә борынгыдан килгән йолаларны, бәйрәм күренешләрне хәтерләп үк җиткермиләр. Шулай да авыл җирендә чын татар әби- бабаларыбыз бар әле. Без укучылар белән авылыбызнын иң өлкән гаиләләрендә кунакта булдык. 3 сыйныф укучысы Мавлютов Айратның әбисе Мөзәйнә апа бала чагындагы авыр,ачлы-туклы,черек бәрәңге ашап тамак туйдырган вакытларын сөйләде.Авылыбызнын иң өлкән акъәбие Гайнуллина Нурсафа әби дә укучыларга тормышның авырлыгын,ничек итеп окоп казуларын,ач-ялангач килеш таякка(ул вакытта акча булмаган) хезмәт көненә эшләүләрен искә алды.Бу вакыттагы кыенлыкларны башка беркемгә дә күрсәтмәсен иде.

Соңгы елларда халкыбызның гореф-гадәтләренә,йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар арта башлады. Шул уңайдан күп кенә бәйрәмнәребез яңадан халык арасына кереп бара.Халкыбызның йола-бәйрәмнәрен,гореф-гадәтләрен торгызу һәм яңарту безнең “Кече Ватан” түгәрәгендә дә актив алып барыла. Милли бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләр, балаларыбызны халык культурасы белән таныштыруда, зур урын алып тора. Халык бәйрәмнәре ул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була.Татар халкының ***Сөмбелә, Сабантуй, Нәүрүз,***

***Нардуган, Корбан гаете,Ураза бәйрәме, каз өмәсе, никах-туй йоласы, бәби туе*** бәйрәмнәре елдан-ел камилләшә, кызыклы итеп оештырыла башлады. Шушы бәйрәмнәрнең кайберләре безнең объединенида да үткәрелә.

Яңа уку елына аяк басу белән, "Кече Ватан" түгәрәгендә дә уңыш бәйрәме, алтын көзне каршылау ***"Сөмбелә"*** бәйрәме белән башланып китә. Елның сихри фасылында, көн белән төн тигезләшкән мәлдә, татар халкы Сөмбелә бәйрәмен үткәргән.

**Өлкәннәр көненә** күп еллар хезмәт иткән өлкәннәребезгә күмәк, җырлы-биюле тамаша театр-тамаша әзерләдек.

***«Аулак өй»***нең нәрсә икәнен мөгаен һәр кеше дә беләдер, чөнки бу гореф гадәт бик борынгыдан килә.Элек, олылар туганнарына яисә эшләре буенча киткәч, кызлар үзләре генә калганнар һәм кунакка дус кызларын чакырганнар. Озакламый аларга егетләр дә килеп кушылган. Зур һәм шаян төркемдә бию һәм җыр, мәзәкләр сөйләү башланган. Егетләр һәм кызлар милли татар уеннары уйнаганнар. Нәкъ менә шул «Аулак өй» татарларның гореф гадәте булып киткән.

Язгы чәчүләр тәмамлангач татар халкы үзенең иң зур бәйрәнәренең берсе булган **Сабантуй** бәйрәмен үткәрә.Сабантуй элек-электән халкыбызның һәрчак яратып,зур күтәренкелек белән үткәрә торган олы бәйрәме. Анда кыр батырларын,көрәшчеләрне,колхоз алдынгыларын бүләклиләр.Бу бәйрәмне үткәрү өчен аерым көн билгеләнмәгән. Ләкин безнең балалар бакчасында "Сабантуй" бәрәме "Балаларны яклау көне" ндә үткәрелә.Шул уңайдан балалар өчен бик күңелле чара үткәрелә. Бәйрәмне оештыруда ата-аналарның да роле зур. Алар һәрдаим безнең зур ярдәмчеләребез. Бәйрәм балалар мәйданчыгында үткәрелә. Бәйрәм балалар өчен ярышлар,көрәшләр,спорт уеннары , җыр-биюләр белән бик кызык һәм мавыктыргыч үтә.

Балага туган телне, халкыбызның гореф-гадәтләрен өйрәнүдә, беренче чара булып **уеннар** тора. Уеннар тәрбия чыганагы буларак, баланың төрле яктан үсүенә йогынты ясый. Аларда катнашу баланың физик көче, җыр-биюгә осталыгын, сүз байлыгын арттырырга ярдәм итә. Күмәк эшләү, ярдәмләшү, шәфкатьлелек, кушканны үтәү кебек уңай сыйфатларны үстерә.

Татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, традицияләре, көнкүреш һәм тел үзенчәлекләре халык уеннарында киң чагылыш таба. Татар халкының уеннарын балалар бик тиз өйрәнәләр һәм бик теләп уйныйлар. Балаларга уен тәкъдим иткәндә, аларның иң яхшы үзләштерә торганнарын сайларга кирәк.

Балалар **хәрәкәтле уеннарга** өстенләк бирәләр һәм без алар белән күбрәк “Мәче һәм тычкан”, “Ябалак”, “Йоклаган песи”, “Очты, очты...”, “Аю-бүре”, “Күрсәт әле үскәнем”, “Милүшә-дилбегә” кебек уеннар уйныйбыз.Уеннардан балалар уңай тәэсир алалар, шулай ук тел байлыгын арттыралар.

Төркемдә балалар белән “Серле капчык”, “Әбием сандыгы”, “Танып бел”, “Йөзек салышлы”, “Ватык телефон” кебек уеннар алына.

**Сюжетлы-рольле** уеннарга да бик зур урын бирелә. Бу балаларга бер-берсенә хөрмәт, әдәплелек хисен үстерергә ярдәм итә. Шулай УК **дидактик уеннарга** да зур урын бирелә. Бу уеннар “Нәрсә артык?”, “Читекнең парын тап”, “Савыт-сабаны бизә”, “Милли киемнәрне бизәү” һ. б. баланың дөрес фикерләү, уйлап табу сәләтен үстерә. Шөгыльләрне уздырганда физминуткалар өчен кызыклы, хәрәкәтле күнекмәләр алабыз.

Безнең “Кече Ватан” түгәрәгендә дә милли хис тәрбияләү түбәндәге юнәлешләрдән чыгып оештырыла:

- балаларга республика,туган як турында мәгълүмат бирү;
- халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;
- әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында кузаллау булдыру;
- туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;
- төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу;
-милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу;
-халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе барлыгын җиткерү.

Объединениеда фольклор элементларын туплап, эш барышында киң кулланабыз. Нинди генә тәрбия чарасы әкият, сынамыш, санамыш, җырлы-биюле яисә хәрәкәтле уеннардан башка үтә микән.

Халык бәйрәмнәре һәм йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Бу бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшьләр бәйрәмнәрнең тәртибен, йоласын кечкендән үк белеп, күреп, өйрәнеп үсәргә тиеш. Балаларга кечкнәдән үк әдәплелек, инсафлык,

мәрхәмәтлелек тәрбияләүдә әти-әниләр, тәрбиячеләр зур эш алып барырга тиеш. Балаларга үз-үзен тота белү, аралаша белү күнекмәләрен балалар бакчасында һәм гаиләдә өйрәтергә кирәк. Әгәрдә без балаларны шушы тәртиптә тәрбияләсәк шул чагында гына милләт, халык өчен тәрбияле балалар үстеребез.

Сегодня у народа, не знающего своей истории, нет будущего. Для этого каждый ребенок должен знать историю своей семьи, родной земли, через нее приближаться к народу. Каждая нация стремилась сохранить сложившиеся на своей территории и передаваемые из поколения в поколение традиции, образ жизни, правила поведения, взгляды, вкусы людей.

Исполнение определенных обрядов в быту, соблюдение традиций и проведение праздников характерно для всех народов. Он считается важной частью культуры этого народа. Обычаи включают в себя праздники, обряды, которые издревле исполнялись народом. Соблюдение определенных обрядов делает общество более стабильным, без них народ не может жить полноценной жизнью.

В общем, наша цель-сохранить родной язык, историю, духовные ценности, традиции, создать прочную связь между поколениями, продолжить жить великой нацией.

И то, что народы Татарстана живут в мире и согласии, является примером толерантности для всего мира. В укреплении дружественных связей между народами большую роль играют праздники, через которые народы изучают культуру, образ жизни, обычаи и традиции друг друга, через которые воспитывают уважение друг к другу, укрепляют дружбу.

В настоящее время национальные праздники, обряды и традиции возрождаются, возрождаются, приобретают современный облик. Если их знает и уважает народ, живет нация, когда живет нация, живет язык, то есть жизнь продолжается.

При воспитании детей в национально-культурном духе создаются условия для формирования высокой нравственной , всесторонне развитой, творческой личности, интересующейся традициями и культурой татарского народа.

Сегодня одна из главных задач, которую я ставлю перед собой, – это целенаправленное обучение детей родному языку, а также ознакомление их с искусством, традициями , праздниками, обычаями, национальной литературой нашего народа.

Одна из основных задач в обучении детей родному языку – опора на литературное богатство, фольклорное наследие нашего народа, его традиции. Воспитание любящего свой язык, уважающего свою национальность человека должно опираться на народную педагогику. Загадки, подсчеты, частушки, сказки, баиты, колыбельные песни – богатейший источник изучения языка.

В связи с тем, что , общение друг с другом, встречи становятся все реже, национальные праздники, обычаи и традиции татарского народа забываются Даже в сельской местности есть люди, которые не знают друг друга. Сегодня многие пожилые люди не помнят древних обрядов, праздничных явлений. И все же в сельской местности есть настоящие татарские бабушки и дедушки. Мы с учениками побывали в гостях у самых старших семей нашего села. Бабушка ученика 3 класса Мавлютова Айрата, Музай апа рассказала,что она в детстве была больна,голодала, ела гнилую картошку.Старшая акәби деревни Гайнуллина Нурсафа также напомнила школьникам о трудностях жизни,о том,как они рыли окопы, работали голодными, плохо одетыми за трудодни (в то время не было денег). Пусть больше никому не придется испытать такого.

В последние годы все больше внимания уделяется традициям,обычаям и праздникам нашего народа. В связи с этим многие наши праздники вновь становятся народными.Возрождение и возрождение традиций и обычаев нашего народа активно ведется и в нашем объндинении “Малая Родина”. Национальные праздники и традиции занимают большое место в приобщении детей к народной культуре. Народные праздники - это одно из мероприятий, объединяющих народ нацией. У каждой нации есть свой праздник.С каждым годом совершенствуются и становятся интересными татарские народные праздники-Сабантуй, Новруз, Нардуган, Курбан-байрам, Ураза-байрам, каз-субботник, бракосочетания, детские праздники. Некоторые из этих праздников проводятся и в нашем объединении.

С началом нового учебного года в объединении “Малая Родина” проводится праздник “Сюмбель” праздник урожая, встреча золотой осени. В это волшебное время года, когда день и ночь сравнялись, татарский народ праздновал праздник Сюмбеля.

Ко дню пожилых людей мы готовим коллективное, песенно - танцевальное представление.

Что такое «Аулак өй», наверное, знает каждый, ведь этот обычай уходит корнями в глубокую древность. Раньше, когда взрослые уходили к родственникам или по делам, девушки оставались одни и приглашали в гости своих подруг. Вскоре к ним присоединились и юноши. В большой и веселой группе начинались танцы и пение, рассказы. Юноши и девушки играли в национальные татарские игры. Именно «Аулак өй», стал традиционным татарским обычаем.

После окончания сева татарский народ проводит Сабантуй, который является одним из самых больших праздников.Сабантуй издревле является большим праздником,проводимым нашим народом с большой любовью и воодушевлением. Там награждают героев полей, борцов, передовиков колхоза. Особого дня для проведения этого праздника не установлено. Но в нашем детском саду “Сабантуй” проводится в “День защиты детей”. В связи с этим для детей проводится развлекательное мероприятие. Большую роль в организации праздника играют родители. Они всегда наши большие помощники. Праздник проводится на детской площадке. Праздник проходит очень интересно и увлекательно для детей с соревнованиями, борьбой, спортивными играми , песнями и танцами.

Первым средством обучения ребенка родному языку, обычаям и традициям нашего народа являются игры. Игры как источник воспитания влияют на всестороннее развитие ребенка. Участие в них помогает повысить физическую силу, певческое и танцевальное мастерство, словарный запас ребенка. Развивает такие положительные качества, как коллективная работа, отзывчивость, доброта, выполнение поручений.

История, обычаи, традиции, бытовые и языковые особенности татарского народа широко отражаются в народных играх. Татарские народные игры дети изучают очень быстро и с удовольствием. Предлагая детям игру, нужно выбрать ту, которая лучше всего их освоит.

Дети отдают предпочтение подвижным играм, и мы больше общаемся с ними: “Кот и мышь”, “Бабочка”, “Спящая кошка”, “Летала, летала"...”,

“Медведь-волк“,” Покажи, что я вырос", "Милуша-дильбега".От игр дети получают положительные эмоции, а также пополняют словарный запас.

В объединении с детьми проводятся такие игры, как “Таиный мешок”, “Бабушкин сундук”, “Узнай”, “Плюшевый мишка”, “Сломанный телефон”.

Большое место уделяется сюжетно-ролевым играм. Это помогает детям воспитывать уважение друг к другу, чувство вежливости. Также большое место отводится дидактическим играм. Это игры “Что лишнего?”, “Найди парочку чужих”, “Укрась посуду”, "Укрась национальные костюмы" и др. При проведении занятий мы получаем интересные, подвижные навыки для физминуток.

В нашем объединении “Малая Родина” воспитание национального чувства организуется исходя из следующих направлений:

- информирование детей о республике, родном крае;

- глубокое знакомство с традициями и обычаями нашего народа;

- создание представления о нашем литературном и культурном достоянии;

- желание говорить на родном языке, уважение к нему;

- знакомство с писателями, людьми искусства, живущими в крае;

-ознакомление с историей национальных праздников, участие в них;

-донести, что существует понятие дружбы между народами, национальностями.

В объединении накапливались фольклорные элементы, которые широко использовались в процессе работы. Какое воспитательное мероприятие не проходит без сказоки, конкурсов, песенно-танцевальных или подвижных игр?

Народные праздники и обряды помогают приучить человека к правилам и требованиям жизни. Эти праздники старшие и младшие жители проводят вместе. Молодежь должна с малых лет знать, видеть, изучать обычаи и традиции праздников. Родители, воспитатели должны с самого раннего возраста вести большую работу по воспитанию в детях вежливости, вежливости, доброты. Детям необходимо прививать навыки поведения, общения в детском саду и в семье. Если мы будем воспитывать детей в таком порядке, то только тогда вырастим детей, достойных нации, народа.